ГОСУДАРСТВЕННАЯ
ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Б.Красная, 15/9, г.Казань, 420111

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ
ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ
Б.Красная ур. 15/9, Казан шәһәре, 420111

тел/факс. 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№_36_

**П Р И К А З** **Б О Е Р Ы К**

«18» ____02___2021 ел.

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2020 елның 16 ноябрендәге 203 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең норматив хокукый актын гамәлдәге Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2020 елның 16 ноябрендәге 203 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Конкурс комиссиясе составына ТР ДТИ җитәкчесе һәм (яки) ул вәкаләт биргән (шул исәптән кадрлар бүлегеннән һәм граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздырыла торган структур бүлекчәсеннән дә) граждан хезмәткәрләре, ТР ДТИ каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре, шулай ук бәйсез экспертлар – фәнни, мәгариф һәм башка оешмаларның граждан хезмәткәрләренең профессиональ хезмәт эшчәнлегенең тиешле өлкәләрендә һәм төрләрендә кадр технологияләре һәм граждан хезмәте мәсьәләләре буенча белгечләр булып торган, законнарда билгеләнгән тәртиптә ТР ДТИ җитәкчесенең рәсми мөрәҗәгате буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан чакыртыла торган вәкилләре керә. Бәйсез экспертның конкурс комиссиясендә булу вакыты өч елдан артмаска тиеш. Бәйсез экспертларның саны

конкурс комиссиясендәге әгъзаларның гомуми санынnан кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итә.

ТР ДТИ каршындагы Иҗтимагый совет әгъзаларының һәм бәйсез экспертларның гомуми саны конкурс комиссиясендәге барлык әгъзалар санының кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итә.».

2. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Башлык С.А. Крайнов